**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2025 елның 9 октябрендәге 3401 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2021 елның 26 маендагы 1306 номерлы «Казан шәһәренең**
**балалар музыка, рәсем сәнгате, спорт, хореография мәктәпләрендә,**
**сәнгать мәктәпләрендә, Н.Г.Җиһанов исемендәге Казан дәүләт**
**консерваториясе каршындагы Урта махсус музыка мәктәбендә,**
**Казан шәһәренең югары һәм һөнәри белем бирү учреждениеләрендә**
**укучылар өчен Казан шәһәре Мэрының исемле стипендияләрен**
**гамәлгә кую турында»гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясенең мәгариф һәм яшьләр сәясәте өлкәсендә норматив-хокукый документлар үзгәрүгә бәйле рәвештә **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 26 маендагы 1306 номерлы «Казан шәһәренең балалар музыка, рәсем сәнгате, спорт, хореография мәктәпләрендә, сәнгать мәктәпләрендә, Н.Г.Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе каршындагы Урта махсус музыка мәктәбендә, Казан шәһәренең югары һәм һөнәри белем бирү учреждениеләрендә укучылар өчен Казан шәһәре Мэрының исемле стипендияләрен гамәлгә кую турында»гы карарына (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 30 ноябрендәге 3136 номерлы, 2022 елның 22 декабрендәге 4582 номерлы, 2024 елның 27 ноябрендәге 4897 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарның 1 номерлы кушымтасын гамәлдән чыккан дип танырга;

1.2. әлеге карарга кушымтаны Казан шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 26 маендагы 1306 номерлы карарына 1 номерлы кушымта дип санарга.

2. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан

Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль өлкә мәсьәләләре буенча урынбасарына йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2025 елның 9 октябрендәге
3401 номерлы карарына
кушымта

**Студентлар һәм аспирантлар арасында**
**Казан шәһәре Мэрының исемле стипендияләренә**
**дәгъва кылуга фәнни-тикшеренү һәм фәнни-гамәли эшләр**
**конкурсы турында нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Казан шәһәре Мэрының исемле стипендияләренә дәгъва кылуга фәнни-тикшеренү һәм фәнни-гамәли эшләр конкурсы (алга таба – Конкурс) Казан шәһәре мәгариф оешмалары студентларын (курсантларын), аспирантларын, ординаторларын һәм адъюнктларын, яшьләр белән эшләү буенча белгечләрне, Казан шәһәрендә эшчәнлек алып баручы яшьләр иҗтимагый берләшмәләре әгъзаларын һәм катнашучыларын Казан шәһәренең шәһәр хуҗалыгы, мәдәният, икътисад, социаль өлкәсендәге фәнни-тикшеренү эшчәнлекләренә җәлеп итү максатыннан ел саен үткәрелә.

1.2. Конкурсны оештыручылар (алга таба – Конкурсның оештыру комитеты) – Казан шәһәренең яшь галимнәр һәм белгечләр советы белән берлектә «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты» муниципаль казна учреждениесе.

1.3. Конкурсның бурычлары:

- Казан шәһәре яшьләренең фәнни-тикшеренү эшчәнлеге белән кызыксынуын арттыру;
- тикшеренү, җитештерү һәм административ эшчәнлек өчен кадрлар потенциалын формалаштыру;
- гамәли әһәмияткә ия инновацион фәнни эшләрне Казан шәһәренең шәһәр хуҗалыгына һәм социаль-мәдәни өлкәсендә гамәлгә кертүгә ярдәм итү.

1.4. Казан шәһәре Мэрының исемле стипендияләре узган уку елында уку-укыту һәм фәнни-тикшеренү эшендә ирешелгән нәтиҗәләрдән чыгып бирелә.

1.5. Казан шәһәре Мэрының исемле стипендияләре бер тапкыр һәм җиңүчегә үз категориясендә бер генә тапкыр бирелә.

## II. Конкурста катнашу шартлары

2.1. Конкурста катнашучылар.

2.1.1. Конкурста 18 яшьтән 35 яшькә кадәрге яшь гражданнар катнаша ала:

- студентлар (курсантлар) – һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирү мәгариф оешмаларында көндезге уку формасы буенча урта һөнәри белем программаларын, бакалавриат программаларын, белгечлек алу программаларын яки магистратура программаларын үзләштерүче затлар (2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә мәгариф турында»гы федераль законның 33 статьясындагы 1 өлешенең 3 пункты нигезендә);

- аспирантлар – югары белем бирү мәгариф оешмаларында һәм фәнни оешмаларда фәнни һәм фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программасы буенча аспирантурада көндезге уку формасы буенча укучы затлар (2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә мәгариф турында»гы федераль законның 33 статьясындагы 1 өлешенең 4 пункты нигезендә);

- адъюнктлар – фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программасы буенча адъюнктурада хәрби яки аңа тәңгәлләштерелгән башка хезмәт, эчке эшләр органнарында хезмәт итүче затлар (2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә мәгариф турында»гы федераль законның 33 статьясындагы 1 өлешенең 5 пункты нигезендә);

- ординаторлар – ординатура программалары буенча белем алучы затлар (2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә мәгариф турында»гы федераль законның 33 статьясындагы 1 өлешенең 6 пункты нигезендә);

- яшьләр белән эшләү буенча белгечләр – Казан шәһәрендә яшьләр сәясәте инфраструктурасында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы тиешле һөнәри квалификациясе булган затлар (2020 елның 30 декабрендәге 489-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә яшьләр сәясәте турында»гы федераль законның 2 статьясындагы 5 пункты нигезендә);

- Казан шәһәрендә эшчәнлек алып бара торган яшьләр иҗтимагый берләшмәләре әгъзалары – әлеге берләшмәләрнең уставлары нормалары нигезендә аларның бурычларын уртак хәл итү белән кызыксынулары тиешле шәхси гаризалар яисә иҗтимагый берләшмә әгъзалары буларак аларның тигез хокуклылыгын тәэмин итү максатыннан иҗтимагый берләшмә әгъзалары санын исәпкә алырга мөмкинлек бирә торган документлар белән рәсмиләштерелә торган физик затлар (1995 елның 19 маендагы 82-ФЗ номерлы «Иҗтимагый

оешмалар турында»гы федераль законның 6 статьясының 1 өлеше нигезендә);

- Казан шәһәрендә эшчәнлек алып баручы яшьләр иҗтимагый берләшмәләрендә катнашучылар – әлеге берләшмәләрнең һәм (яисә) аларның конкрет акцияләренең максатларына ярдәм күрсәтү теләге белдергән, уставта башкача каралмаган булса, аларның эшчәнлегендә үзләренең катнашу шартларын мәҗбүри рәсмиләштермичә катнаша торган физик затлар (1995 елның 19 маендагы 82-ФЗ номерлы «Иҗтимагый оешмалар турында»гы федераль законның 6 статьясының 5 өлеше нигезендә).

Конкурста катнашу хокукына Россия Федерациясе гражданнары гына ия.

Казан шәһәре территориясеннән читтә урнашкан мәгариф һәм фәнни оешмаларның, филиалларының студентларына (курсантларына), аспирантларына, адъюнктларына һәм ординаторларына, яшьләр белән эшләүче белгечләргә, яшьләр иҗтимагый берләшмәләре әгъзаларына һәм катнашучыларына Конкурста катнашырга рөхсәт ителми.

Конкурста фән кандидатлары һәм докторлары катнаша алмый.

2.1.2. Казан шәһәре Мэрының исемле стипендияләренә дәгъва кылучы укучыларның «канәгатьләнерлек» билгесе һәм узган уку елы өчен арадаш аттестация нәтиҗәләре буенча академик бурычы булмаска тиеш.

2.1.3. Автордашлык белән башкарылган яки авторлар коллективы тарафыннан тәкъдим ителгән эшләр Конкурста катнашмый.

2.2. Казан шәһәре Мэрының исемле стипендиясенә дәгъва кылуга кандидатлар түбәндәгеләр тарафыннан тәкъдим ителә:

- мәгариф һәм фәнни оешмалар җитәкчеләре (мәгариф оешмасы/фәнни оешма җитәкчесе яисә аның тарафыннан вәкаләт бирелгән заты [профильле проректор/җитәкче урынбасары, структур бүлек җитәкчесе]);

- мәгариф оешмаларының һәм фәнни оешмаларның галимнәр (педагогик, фәнни-техник) советы;

- яшь галимнәр, мәгариф һәм фәнни оешмалар белгечләре советы.

2.3. Конкурска Казан шәһәре өчен гамәли әһәмияткә ия булган фәнни эшләр кабул ителә.

2.4. Конкурс эшләре әлеге Нигезләмәнең 1 номерлы кушымтасында китерелгән Казан шәһәрендә шәһәр хуҗалыгының, социаль өлкәнең һәм яшьләр сәясәтенең өстенлекле юнәлешләрен гамәлгә ашыру проблемаларын хәл итүгә юнәлдерелгән булырга тиеш.

2.5. Стипендияләр түбәндәге күләмдә билгеләнә:

- аспирантлар, ординаторлар, адъюнктлар өчен – бер тапкыр бирелә торган һәркайсы 50 мең сумлык 16 стипендия;

- югары уку йортлары студентлары, яшьләр белән эшләү буенча белгечләр, яшьләр иҗтимагый берләшмәләре әгъзалары һәм катнашучылары өчен – бер тапкыр бирелә торган һәркайсы 35 мең сумлык 20 стипендия;

- һөнәри белем бирү учреждениеләре студентлары өчен – бер тапкыр бирелә торган һәркайсы 30 мең сумлык 2 стипендия (Казан шәһәре Башкарма комитетының 2022 елның 22 декабрендәге 4582 номерлы карарының 2.5 пункты нигезендә).

## III. Эшләрне Конкурска тәкъдим итү вакыты һәм тәртибе

Конкурста катнашу өчен гаризаны kazankddm@yandex.ru адресы буенча почтага җибәрергә, шулай ук электрон рәвештә https://myrosmol.ru сайтында «Россия яшьләре» автоматлаштырылган мәгълүмат системасы аша әлеге Нигезләмә Конкурсны оештыру комитетының социаль челтәрләрендә рәсми басылып чыккан көннән 2025 елның 29 октябрендә 23 сәгать 59 минутка кадәр бирергә кирәк. Гаризага түбәндәге документлар теркәлә:

а) әлеге Нигезләмәнең 2.2 пунктында күрсәтелгән оешма яисә коллегиаль органнар җитәкчесенең, имза һәм мөһер белән таныклап һәм рәсми яисә гомуми (фирма) бланкта рәсмиләштереп, Казан шәһәре Мэрының исемле стипендиясенә дәгъва кылучы кандидатны күрсәтү турында тәкъдимнамәсе-рекомендациясе. Мәгариф учреждениесе кафедрасы утырышы беркетмәсеннән өземтәләр кабул ителми;

б) белем бирү оешмалары студентлары өчен соңгы ике семестр буенча зачет кенәгәсеннән өземтә (яисә таныкланган күчермә); белем бирүнең 2 нче һәм аннан соңгы елларындагы аспирантлар, ординаторлар һәм адъюнктлар өчен еллык аттестация беркетмәсеннән өземтә;

в) 1 нче ел укучы магистрлар, аспирантлар, ординаторлар һәм адъюнктлар өчен юллаучы оешма тарафыннан расланган диплом һәм дипломга кушымталар күчермәләре;

г) Казан шәһәре Мэрының исемле стипендияләренә дәгъва кылуга фәнни-тикшеренү һәм фәнни-гамәли эшләр конкурсында катнашу өчен анкета (әлеге Нигезләмәгә 2 номерлы кушымта)

д) исемле премия алуга дәгъва кылучының узган уку елында фәнни эшчәнлектәге уңышларын раслый торган белешмәләр булган анкетасы (әлеге Нигезләмәгә 3 номерлы кушымта):

1) «Россия фәнни мәгълүмат үзәге» федераль дәүләт бюджет учреждениесе оператор булып торган Ак исемлектәге (алга таба – Ак исемлек) журналларда

бастырылган мәкаләләр;

2) Россия Федерациясе Фән һәм югары белем бирү министрлыгы каршындагы Югары аттестация комиссиясе раслаган Фәннәр кандидаты гыйльми дәрәҗәсен алуга, фәннәр докторы гыйльми дәрәҗәсен алуга диссертацияләрнең төп фәнни нәтиҗәләре басылып чыгарылырга тиешле рецензияләнә торган фәнни басмалар исемлегенә (алга таба – Югары аттестация комиссиясе исемлеге) кертелгән журналларда бастырылган мәкаләләр;

3) Россия фәнни цитаталау индексында индексацияләнә торган журналларда бастырылган мәкаләләр;

4) конкурсларда, конференцияләрдә катнашу һәм бүләкләр;

5) билгеләнгән тәртиптә хокуклар теркәлгән, патент яисә теркәү турында таныклык рәвешендә рәсмиләштерелгән авторы һәм (яисә) хокук иясе булып исемле премия алуга дәгъва кылучы торган, әлеге Нигезләмәгә 3 номерлы кушымтада күрсәтелгән таләпләр нигезендә рәсмиләштерелгән интеллектуаль эшчәнлекнең аерым нәтиҗәләре (электрон исәпләү машиналары өчен программалар (ЭВМ өчен программалар); мәгълүматлар базалары; файдалы модельләр; сәнәгатьтәге үрнәкләре; селекция казанышлары; интеграль микросхема топологияләре).

Тәкъдим итеәә торган материаллар Конкурска бирелә торган эш тематикасына туры килергә тиеш;

е) шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә кулдан тутырылган ризалык (әлеге Нигезләмәгә 4 номерлы кушымта);

ж) әлеге Нигезләмәнең IV бүлеге, 5 номерлы һәм 7 номерлы кушымталары нигезендә рәсмиләштерелгән конкурс эше;

е) күләме бер бит булган һәм әлеге Нигезләмәнең 6 номерлы кушымтасында күрсәтелгән таләпләр нигезендә рәсмиләштерелгән эш тезислары (doc форматында).

Конкурсның оештыру комитеты килеп ирешкән конкурс материалларын, 2025 елның 1 ноябреннән дә соңга калмыйча, электрон почта аша юнәлешләр (секцияләр) буенча Конкурсның эксперт советларына җибәрә.

## IV. Конкурска тәкъдим итеәә торган эшләргә таләпләр

4.1. Конкурска тәкъдим ителүче эш Word текст редакторында тиешле параметрлар нигезендә башкарылырга тиеш:

- битнең юнәлеше – китап бите;
- кырлар: өс – 2 см, ас – 2 см, сул – 2 см, уң – 1 см;

- шрифт – Times New Roman, зурлыгы – 14;
- кызыл юл – 1,25 см;
- юллар арасындагы интервал – бер ярымлы;
- юлдан юлга күчерү – автомат рәвештә;
- тигезләү – киңлек буенча.

4.2. Тапшырыла торган эш күләме – кушымталарны кертмичә, машинкада бастырылган 25 кәгазь битеннән артык түгел.

4.3. Тапшырыла торган эшнең структурасы һәм эчтәлеге әлеге Нигезләмәгә 5 номерлы кушымтада бирелгән таләпләргә туры килергә тиеш.

4.4. Эштә дөрес булмаган алынмалар һәм (яисә) дөрес булмаган цитаталар булырга тиеш түгел. Тулысынча яисә өлешчә генератив ясалма интеллект кулланып әзерләнгән конкурс эшләрен тапшыру рөхсәт ителми. Әлеге таләпкә туры килми торган конкурс эшләрен тапшырган катнашучылар Конкурсның турыдан-туры катнашу этабына кертелми.

4.5. Барлык теркәлә торган файлларның исемендә авторның фамилиясе һәм инициаллары, документның исеме күрсәтелә (мәсәлән, И.В.Иванов. Конкурс эше.doc.).

## V. Иҗтимагый совет вәкаләтләре һәм эш тәртибе

5.1. Конкурсның Иҗтимагый советы Казан шәһәрендә эшчәнлек алып баручы мәгариф, фәнни һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре вәкилләреннән (һәр оешмадан бер генә вәкил) төзелә һәм Казан шәһәре Башкарма комитеты карары белән раслана.

5.2. Иҗтимагый совет составы әлеге Нигезләмәнең 9 номерлы кушымтасында китерелә.

5.3. Конкурсның Иҗтимагый советы, 2025 елның 20 октябреннән дә соңга калмыйча, конкурсның һәр юнәлеше (секциясе) буенча Конкурсның эксперт советларын формалаштыру һәм раслау максатларыннан утырыш үткәрә.

5.4. Эксперт советларын төзү һәм раслау Конкурсның Иҗтимагый советы әгъзалары тавыш бирү юлы белән гамәлгә ашырыла.

5.5. Конкурсның Иҗтимагый советы утырышта Конкурсның Иҗтимагый советы әгъзаларының 50 проценттан артыгы катнашса, тулы хокуклы дип санала.

5.6. Конкурсның Иҗтимагый советы Конкурс утырышында катнашучы Иҗтимагый совет әгъзаларының, ачык тавыш биреп, гади күпчелек тавыш белән кабул ителгән карарлары нигезендә эксперт советларын раслый. Конкурсның

эксперт советлары биш юнәлеш (секцияләр) буенча формалаша: табигый һәм медицина фәннәре, техник һәм авыл хуҗалыгы фәннәре, социаль фәннәр, гуманитар фәннәр һәм яшьләр сәясәте. Конкурсның һәр юнәлешендә (секцияләрендә) бишәр кеше билгеләнә.

5.7. Конкурсның Иҗтимагый советының эксперт советларын формалаштыру турындагы карары беркетмә форматында рәсмиләштерелә. Аны Конкурсның Иҗтимагый советы рәисе имзалый.

5.8 Конкурсның Иҗтимагый советының эксперт советларын формалаштыру турындагы карары, 2025 елның 24 октябреннән дә соңга калмыйча, Конкурсның оештыру комитеты рәсми сайтында (https://kddm.kzn.ru) урнаштырыла.

## VI. Эксперт советын формалаштыру һәм аның эшләве, эшләрне карап тикшерү һәм Казан шәһәре Мэрының исемле стипендияләрен бирү тәртибе

6.1. Казан шәһәре Мэрының исемле стипендияләренә дәгъва кылуга конкурс ике этапта уздырыла:

- читтән торып эшләү этабы: 2025 елның 1 ноябреннән 2025 елның 9 ноябренә кадәр;
- турыдан-туры катнашу этабы: 2025 елның 24 ноябреннән 2025 елның 28 ноябренә кадәр.

6.2. Тапшырылган эшләргә экспертизаны Казан шәһәренең төрле фән тармакларында эшләүче югары белем бирү, фәнни һәм иҗтимагый оешмаларының әйдәүче белгечләреннән, шулай ук Казан шәһәре администрациясе вәкилләреннән торган эксперт советлары башкара.

6.3. Эксперт советлары составы Конкурска тәкъдим ителгән эшләр тематикасыннан чыгып формалаштырыла: Конкурс уздыру вакытына гамәлдә булган фәнни белгечлекләр төркемнәре, Россия Федерациясе Фән һәм югары белем министрлыгы тарафыннан расланган Гыйльми дәрәҗәләр бирелә торган фәнни белгечлекләр номенклатурасы буенча паритетлы нигездә.

Эксперт советлары төзегәндә һәр эшнең тиешле тематикага туры килә торган фәнни белгечлекләр буенча гыйльми дәрәҗәсе булган кимендә ике эксперт советы әгъзасы тарафыннан бәяләнергә тиешлеге исәпкә алынырга тиеш.

Эксперт советы әгъзалары экспертлар советы составында бушлай эшлиләр.

Исемле стипендияләргә дәгъва кылучыларның фәнни җитәкчеләре

Иҗтимагый совет һәм эксперт комиссиясе әгъзалары була алмый.

6.4. Әгәр Иҗтимагый совет тарафыннан расланган составның кимендә өчтән икесе катнашса, эксперт советы утырышы тулы хокуклы дип санала.

6.5. Эксперт советлары үз составыннан эксперт советы рәисен, рәис урынбасарын сайлый.

6.6. Эксперт советы утырышын эксперт советы рәисе алып бара, ә ул булмаганда – эксперт советы рәисе урынбасары яисә эксперт советы карары буенча эксперт советы әгъзаларының берсе.

6.7. Конкурс материалларына экспертиза (читтән торып эшләү этабы) әлеге Нигезләмәгә 8 номерлы кушымтада билгеләнгән критерийларга туры китереп уздырыла.

6.8. Читтән торып эшләү этабы кысаларында эксперт советлары конкурс материалларын 2.1.1 – 2.1.3, 2.2 – 2.4, III һәм IV бүлекләрдә, әлеге карарга 5 номерлы кушымтада күрсәтелгән таләпләргә туры килүләрен тикшерә. Конкурс эше таләпләргә туры килмәгән очракта, эксперт советы катнашучыларны турыдан-туры катнашу этабына кертми.

6.9. Читтән торып уздырылган этап нәтиҗәләре буенча эксперт советлары Конкурсның турыдан-туры катнашу этабына үткән катнашучылар исемлекләрен раслыйлар. Карар утырышларда катнашучы эксперт советлары әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә һәм эксперт советы рәисе тарафыннан имзаланган беркетмә рәвешендә рәсмиләштерелә.

6.10. Конкурсның турыдан-туры катнашу этабына узган катнашучылар исемлеге рәсми сайтта (https://kddm.kzn.ru) һәм Конкурсның оештыру комитеты социаль челтәрләрендә (https://vk.com/kddm_kazan), эксперт советлары утырышлары уздырылганнан соң, 3 көннән дә соңга калмыйча бастырыла.

6.11. Турыдан-туры катнашу этабын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында, мәгълүматны рәсми сайтта (https://kddm.kzn.ru) һәм Конкурсның оештыру комитеты социаль челтәрләрендә (https://vk.com/kddm_kazan) бастырып, катнашучыларга хәбәр ителә.

6.12. Конкурсантлар үз эшләрен Конкурсның турыдан-туры катнашу этабы булган фәнни-гамәли конференция барышында яклыйлар. Конкурсның турыдан-туры катнашу этабы биш юнәлеш (секцияләр) буенча уздырыла:

- табигый һәм медицина фәннәре;
- техник һәм авыл хуҗалыгы фәннәре;
- социаль фәннәр;
- гуманитар фәннәр;
- яшьләр сәясәте.

Конкурс юнәлеше исемле стипендиягә дәгъва кылучы тарафыннан Конкурска гариза бирү этабында мөстәкыйль рәвештә сайлана һәм Конкурс барышында үзгәртелә алмый.

6.13. Турыдан-туры катнашу этабында Конкурста катнашучылар Конкурсның эксперт советлары әгъзалары каршында үз эшләрен тәкъдим итәләр. Конкурсның эксперт советлары әгъзалары тәкъдим ителгән эшләрне әлеге Нигезләмәгә 8 номерлы кушымтада бирелгән критерийлардан чыгып бәялиләр. Конкурсның эксперт советлары әгъзалары әлеге Нигезләмәгә 10 номерлы кушымта нигезендәге форма буенча бәяләү кәгазен тутыралар.

6.14. Конкурсның һәр юнәлешендә (секциясендә) иң күп балл җыйган катнашучылар җиңүче була. Алар конкурста стипендияләрнең юнәлешләр (секцияләр) буенча пропорциональ бүленешен исәпкә алып, 2.5 пунктында тәкъдим ителгән катнашучылар санына карап билгеләнә.

Берничә катнашучы бертигез санда баллар җыйган очракта, эксперт советлары утырышта катнашучы эксперт советлары әгъзалары саныннан күпчелек тавыш белән иң яхшы конкурс эшен билгеләү буенча карар кабул итә.

6.15. Конкурстагы эксперт советларының Казан шәһәре Мэрының исемле стипендияләрен бирү турындагы карары һәр юнәлеш (секция) буенча беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм, турыдан-туры катнашу этабы тәмамланганнан соң, 3 эш көненнән дә соңга калмыйча, Конкурсның оештыру комитетына җибәрелә.

6.16 Эксперт советы карарлары кабат карап тикшерелми. Конкурс эшләрен бәяләү баллары белән нәтиҗә беркетмәләре катнашучыларга аларның үтенече буенча бирелә.

6.17. Бүләкләү тантанасын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында, чарага кадәр кимендә өч эш көне кала рәсми сайтта (https://kddm.kzn.ru) һәм Конкурсның оештыру комитетының социаль челтәрләрендә (https://vk.com/kddm_kazan) мәгълүмат бастырып, Конкурста җиңүчеләргә хәбәр ителә.

6.18. Конкурста җиңүчеләргә Казан шәһәре Мэрының махсус дипломнары һәм исемле стипендияләре тапшырыла. Казан шәһәре Мэрының исемле стипендияләре бүләкләү көнендә бер тапкыр бирелә.

6.19. Конкурсның эксперт советлары эшендә ике елдан артык рәттән катнашкан эксперт советы әгъзалары Казан шәһәре Башкарма комитетының һәм (яисә) «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты» муниципаль казна учреждениесенең рәхмәт хатлары белән бүләкләнәләр.

________________

Студентлар һәм аспирантлар арасында
Казан шәһәре Мэрының исемле
стипендияләренә дәгъва кылуга
фәнни-тикшеренү һәм фәнни-гамәли
эшләр конкурсы турында нигезләмәгә
1 номерлы кушымта

**Студентлар һәм аспирантлар арасында Казан шәһәре Мэрының исемле стипендияләренә дәгъва кылуга фәнни-тикшеренү һәм фәнни-гамәли эшләр конкурсы юнәлешләре исемлеге**

1. Табигый һәм медицина фәннәре.
2. Техник һәм авыл хуҗалыгы фәннәре.
3. Социаль фәннәр.
4. Гуманитар фәннәр.
5. Яшьләр сәясәте

Студентлар һәм аспирантлар арасында
Казан шәһәре Мэрының исемле
стипендияләренә дәгъва кылуга
фәнни-тикшеренү һәм фәнни-гамәли
эшләр конкурсы турында нигезләмәгә
2 номерлы кушымта
(Форма)

**Студентлар һәм аспирантлар арасында Казан шәһәре Мэрының исемле стипендияләренә дәгъва кылуга фәнни-тикшеренү һәм фәнни-гамәли эшләр конкурсында катнашу өчен анкета**

| | |
|---|---|
| **Фамилиясе** | |
| **Исеме** | |
| **Атасының исеме** | |
| **Оешма, тулы исеме** | |
| **Мобиль телефон** | |
| **Электрон почта адресы** | |
| **Конкурс эше атамасы** | |
| **Конкурс юнәлеше** | |
| **Конкурс материалларына электрон сылтама** | |

Студентлар һәм аспирантлар арасында
Казан шәһәре Мэрының исемле
стипендияләренә дәгъва кылуга
фәнни-тикшеренү һәм фәнни-гамәли
эшләр конкурсы турында нигезләмәгә
3 номерлы кушымта
(Форма)

**Казан шәһәре Мэрының исемле стипендиясенә**
**дәгъва кылучы анкетасы**

1. Исемле стипендиягә дәгъва кылучыны Конкурска тәкъдим итә торган мәгариф, фән яисә яшьләр оешмасының атамасы: ______________________ ______________________________________________________________________.

2. Исемле стипендиягә дәгъва кылучының фамилиясе, исеме, атасының исеме _________________________________________________________________.

3. Бакалавр, магистрант, аспирант, _____курс, уку формасы ______________.

4. Конкурс эшенең исеме:_______________________________________________.

5. Студентлар һәм аспирантлар арасында Казан шәһәре Мэрының исемле стипендияләренә дәгъва кылуга фәнни-тикшеренү һәм фәнни-гамәли эшләр конкурсы турындагы нигезләмәгә 1 номерлы кушымта нигезендә конкурс эше юнәлеше*: ______________________________________________________.

6. Фәнни җитәкче: ______________________________________________.

7. Исемле стипендиягә дәгъва кылучының уку (эш) урыны турында мәгълүматлар: студент (курсант)/аспирант/ординатор, факультет (бүлек, эш урыны), белгечлек ________________________________________________ .

8. Исемле стипендиягә дәгъва кылучының фәнни эшчәнлегендә ирешкән уңышлары турында мәгълүматлар (бастырылган хезмәтләр исемлеге (категорияләр буенча), конкурсларда, конференцияләрдә катнашу, бүләкләр h.б.):_______________________________________________________________.

9. Исемле стипендиягә дәгъва кылучының туу датасы:________________.

10. Элемтә телефоннары ____________________________________________.

11. Теркәлү урыны буенча адресы: ___________________________________.

12. Паспорт мәгълүматлары: сериясе______номеры ____________________
_____________________________________________ тарафыннан бирелгән.

13. Салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры _________________________.

14. Пенсия иминиятләштерүе таныклыгы номеры_______________________.

Анкетаны тутыру датасы _____________________

Исемле стипендиягә дәгъва кылучының имзасы ___________________

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык бирәм ____________________

(исемле стипендиягә дәгъва кылучының имзасы)

* Әгәр конкурс эше дисциплинаара характерда булса, Студентлар һәм аспирантлар арасында Казан шәһәре Мэрының исемле стипендияләренә дәгъва кылуга фәнни-тикшеренү һәм фәнни-гамәли эшләр конкурсы турындагы нигезләмәгә 1 номерлы кушымта нигезендә күрсәтелгән юнәлешләр саны икедән артмаска тиеш.

Студентлар һәм аспирантлар арасында
Казан шәһәре Мэрының исемле
стипендияләренә дәгъва кылуга
фәнни-тикшеренү һәм фәнни-гамәли
эшләр конкурсы турында нигезләмәгә
4 номерлы кушымта
(Форма)

«Казан шәһәре Башкарма комитетының
Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты»
муниципаль казна учреждениесе
Салым түләүченең тәңгәлләштерү
номеры: 1655065603
Төп дәүләт теркәү номеры:
1061655000109
Адрес: 420107, Казан шәһәре,
Петербург урамы, 70 йорт

___________________________________
(шәхси мәгълүматлар субъектының фамилиясе, исеме,
атасының исеме (булган очракта))
телефон номеры, электрон почта
адресы:
__________________________________
__________________________________

**Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык**

Мин, _______________________________________________________________,
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
паспорт________________________ __________________________________________,
(сериясе, номеры) (кайчан һәм кем тарафыннан бирелгән)
теркәлү адресы: ________________________________________________________,
2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында»гы федераль законның 9 статьясы нигезендә «Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты» муниципаль казна учреждениесенә, Студентлар һәм аспирантлар арасында Казан шәһәре Мэрының исемле стипендияләренә дәгъва кылуга фәнни-тикшеренү һәм фәнни-гамәли эшләр конкурсының Иҗтимагый советына һәм эксперт советына (алга таба – Конкурсны оештыручылар) үземне идентификацияләү һәм Конкурста катнашу

максатыннан, җыюны, системалаштыруны, туплауны, саклауны, төгәлләштерүне (яңартуны, үзгәртүне), куллануны, таратуны (шул исәптән тапшыруны), шәхси үзенчәлекләрне бетерүне, тыюны, шәхси мәгълүматларны юк итүне һәм тикшерүне кертеп, үземнең шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык бирәм.

Эшкәртүгә ризалык бирелгән шәхси мәгълүматлар исемлеге:

1) фамилия, исем, атасы исеме (соңгысы – булган очракта)
2) уку урыны, белем дәрәҗәсе, факультет, уку курсы (елы);
3) теркәлү адресы;
4) туу датасы;
5) телефон номеры;
6) электрон почта адресы;
7) паспорт мәгълүматлары (сериясе, номеры, бирү датасы);
8) салым түләүченең тәңгәлләштерү номеры;
9) пенсия иминияте таныклыгының номеры;
10) басылып чыккан хезмәтләр турында, конкурсларда һәм конференцияләрдә катнашу турында, бүләкләр һәм интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләре турында мәгълүматлар.

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык бирелгән шәхси мәгълүматлар белән гамәлләр исемлеге: 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында»гы федераль закон һәм Россия Федерациясенең башка норматив актлары нигезендә җыю, системалаштыру, туплау, саклау, төгәлләштерү (яңарту, үзгәртү), куллану (шул исәптән тапшыру), шәхси үзенчәлекләрне бетерү, тыю, юк итү.

Конкурсны оештыручылар, шәхси мәгълүматлар субъектларының шәхси мәгълүматларын эшкәртү өчен автоматлаштырылган чаралар кулланып, шулай ук автоматлаштырылган чаралар кулланмыйча, шәхси мәгълүматларны эшкәртүне гамәлгә ашыра.

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыкның гамәлдә булу вакыты: әлеге ризалык аны имзалаган көннән алып шәхси мәгълүматлар субъекты аны язма рәвештә кире кайтарган көнгә кадәр гамәлдә була.

Мондый ризалыкны биргәндә, үз теләгем белән һәм үз мәнфәгатьләремдә эш итүемне раслыйм.

2025 елның «____»___________ _____________/____________________

(имза) (имзаның аңлатмасы)

Студентлар һәм аспирантлар арасында
Казан шәһәре Мэрының исемле
стипендияләренә дәгъва кылуга
фәнни-тикшеренү һәм фәнни-гамәли
эшләр конкурсы турында нигезләмәгә
5 номерлы кушымта

**Конкурс эшенең структурасына һәм эчтәлегенә карата таләпләр**

Конкурс эшенең гомуми күләме, кушымталардан тыш, А4 форматындагы 25 биттән артмаска тиеш.

Конкурс эше түбәндәге өлешләрдән торырга тиеш: титул бите, кыскача аннотация, төп сүзләр, кереш, төп өлеш, йомгаклау, файдаланылган әдәбият исемлеге. Кирәк булган очракта конкурс эшенә кушымталар рәвешендә өстәмә материаллар теркәп бирелергә мөмкин.

Титул битендә түбәндәге мәгълүмат булырга тиеш:

- исемле стипендиягә дәгъва кылучыны конкурска тәкъдим иткән оешма атамасы;
- конкурс эшенең исеме;
- Студентлар һәм аспирантлар арасында Казан шәһәре Мэрының исемле стипендияләренә дәгъва кылуга фәнни-тикшеренү һәм фәнни-гамәли эшләр конкурсы турындагы нигезләмәгә 1 номерлы кушымта нигезендә эш Конкурска тапшырыла торган юнәлеш;
- Конкурсның турыдан-туры катнашу этабы юнәлеше;
- исемле стипендиягә дәгъва кылучының фамилиясе, исеме, атасының исеме;
- фәнни җитәкчененң фамилиясе, исеме, атасының исеме, вазифасы, гыйльми дәрәҗәсе (булган очракта).

Күләме бер биттән артмаган кыска аннотациядә түбәндәге мәгълүмат булырга тиеш:

- актуальлек;
- яңалык;
- эшнең гамәли әһәмияте;
- башкарылган эш йомгаклары буенча чыгарылган нәтиҗәләр һәм Конкурсның өстенлекле юнәлешләре нигезендә аларны куллану мөмкинлеген бәяләү.

Төп сүзләр.

Керештә булырга тиеш: актуальлекне нигезләү; эшнең максаты һәм бурычлары; тикшеренү объекты, предметы, ысуллары; эш нәтиҗәләрен (булган очракта) сынап карау һәм гамәлгә кертү (өч биткә кадәр).

Конкурс эшенең төп өлеше эштә күтәрелүче мәсьәлә тарихын, бу өлкәдә тикшеренүләрне кыскача анализлау һәм аларның нәтиҗәләрен чагылдырырга тиеш. Эшнең төп өлешендә тикшеренү объекты, предметы, ысуллары җентекләп каралырга, тикшеренү нәтиҗәләре китерелергә тиеш, эштә китерелгән мәгълүматларга анализ нигезендә нәтиҗәләр ясалырга тиеш (20 биткә кадәр).

Йомгаклау өлешендә эш буенча гомумиләштерелгән нәтиҗәләр, гамәлгә ашыру нәтиҗәләре (булган очракта), аларны Конкурс тематикасы нигезендә куллану мөмкинлекләрен бәяләү булырга тиеш (ике биткә кадәр).

Файдаланылган әдәбият исемлеге.

Студентлар һәм аспирантлар арасында
Казан шәһәре Мэрының исемле
стипендияләренә дәгъва кылуга
фәнни-тикшеренү һәм фәнни-гамәли
эшләр конкурсы турында нигезләмәгә
6 номерлы кушымта

**Тезисларны рәсмиләштерүгә таләпләр**

Доклад тезислары күләм буенча тулы бер битне тәшкил итәргә тиеш. Доклад тезисларын түбәндәге таләпләр нигезендә рәсмиләштерү зарур: текст Word редакторында җыела, юллар арасындагы интервал – 1,0, шрифт – Times New Roman, зурлыгы – 12, абзац чигенеше – 1,25 см, бит форматы – А4 (машинада җыелган стандарт бит), текст киңлек буенча тигезләнә, сүзләр юлдан-юлга күчерелми, кырлар һәр яктан 2 см га тигез.

Докладның исеме ярымкалын шрифт белән баш хәрефләрдә бирелә, үзәк буенча тигезләнә. Бер буш юл калдырып, авторның инициаллары, фамилиясе, курсы яисә уку елы күрсәтелә, үзәк буенча тигезләнә; фәнни җитәкченең инициаллары, фамилиясе, гыйльми дәрәҗәсе, вазифасы күрсәтелә, үзәк буенча тигезләнә; оешма атамасы, e-mail адресы, үзәк буенча тигезләнә. Бер буш юл калдырып, кызыл юлдан тезислар тексты языла.

Файл исемендә авторның инициаллары, фамилиясе күрсәтелә (мәсәлән, И.В.Иванов Тезислар.doc).

Докладның тезисларын рәсмиләштерү үрнәге:

**КОЯШ ЭНЕРГЕТИКАСЫ ИХТЫЯҖЛАРЫ ӨЧЕН КРЕМНИЙ АЛУНЫҢ ЯҢА ЫСУЛЫН ЭШЛӘП ЧЫГАРУ**

И.И.Иванов, 4 нче курс студенты
П.А.Сидоров, техник фәннәр докторы, профессор, фәнни җитәкче
Казан (Идел буе) федераль университеты
e-mail: ivanov@mail.ru

Текст. Текст. Текст. Текст. Текст. Текст. Текст. Текст. Текст. Текст. Текст. Текст. Текст.

Студентлар һәм аспирантлар арасында
Казан шәһәре Мэрының исемле
стипендияләренә дәгъва кылуга
фәнни-тикшеренү һәм фәнни-гамәли
эшләр конкурсы турында нигезләмәгә
7 номерлы кушымта

Студентлар һәм аспирантлар арасында
Казан шәһәре Мэрының исемле стипендияләренә дәгъва кылуга
фәнни-тикшеренү һәм фәнни-гамәли эшләр конкурсы

**КОНКУРС ЭШЕ**

темасы:

**«ЭШНЕҢ ИСЕМЕ»**

Конкурсның юнәлеше:

«__________________________________________»

Эш башкарылган фәнни белгечлекләр төркеме исеме:

«____________________________________________»

Башкарды: ____________
(имза)

Студент/аспирант фамилиясе, исеме, атасының исеме (тулысынча), исемле стипендиягә дәгъва кылучыны конкурска тәкъдим иткән оешма атамасы

Фәнни җитәкче: ____________________
(имза)
Фәнни җитәкченең фамилиясе, исеме, атасының исеме (тулысынча), вазифасы, гыйльми дәрәҗәсе, гыйльми исеме (булган очракта)

**Казан – 2025**

Студентлар һәм аспирантлар арасында
Казан шәһәре Мэрының исемле
стипендияләренә дәгъва кылуга
фәнни-тикшеренү һәм фәнни-гамәли
эшләр конкурсы турында нигезләмәгә
8 номерлы кушымта

**Казан шәһәре Мэры стипендияләренә дәгъва кылуга конкурска тәкъдим ителгән эшләрне бәяләү критерийлары**

| Конкурсны бәяләү этабы | Критерий | Баллар | Кыскача аңлатма |
|---|---|---|---|
| Читтән торып катнашу | Эшнең эчтәлеге конкурс юнәлешләренә туры килүе | 0-1 | 0 – туры килми<br>1 – Конкурс турындагы нигезләмәгә туры килә |
| Читтән торып катнашу | Эшнең эчтәлеге Казан шәһәренең шәһәр хуҗалыгы, мәдәният, икътисад, социаль өлкә мәнфәгатьләренә туры килүе | 0-1 | 0 – туры килми<br>1 – Конкурс турындагы нигезләмәгә туры килә |
| Турыдан-туры катнашу | Эшнең актуальлеге | 0-10 | 0 – юк;<br>10 – актуальлеккә ия |
| Турыдан-туры катнашу | Эшнең фәнни яктан яңалыгы | 0-10 | 0 – юк;<br>10 – фәнни яңалыкка ия |
| Турыдан-туры катнашу | Проектны (эшне) гамәлгә ашыру һәм алга таба үстерү мөмкинлеге | 0-10 | 0 – алга таба проектның нәтиҗәләрен тормышка ашыру мөмкин түгел;<br>10 – алга таба гамәлгә ашыру мөмкин |
| Читтән торып катнашу | Эшнең структурасы һәм аны тутыру | 0-1 | 0 – туры килми<br>1 – туры килә |
| Читтән торып катнашу | Ак исемлектәге журналларда бастырылган мәкаләләр | 0-1 | 0 – бастырылган мәкаләләр юк;<br>1 – бастырылган мәкаләләр бар |
| Читтән торып катнашу | Югары аттестация комиссиясе исемлегендәге журналларда бастырылган мәкаләләр | 0-1 | 0 – бастырылган мәкаләләр юк;<br>1 – бастырылган мәкаләләр бар |
| Читтән торып катнашу | Россия фәнни цитаталау индексында индексацияләнә торган журналларда бастырылган | 0-1 | 0 – бастырылган мәкаләләр юк;<br>1 – бастырылган мәкаләләр бар |

| Конкурсны бәяләү этабы | Критерий | Баллар | Кыскача аңлатма |
|---|---|---|---|
| | мәкаләләр | | |
| Читтән торып катнашу | Конкурсларда, конференцияләрдә катнашу һәм бүләкләр | 0-1 | 0 – бастырылган язмалар юк;<br>1 – бастырылган язмалар бар |
| Читтән торып катнашу | Интеллектуаль эшчәнлекнең теркәлгән нәтиҗәләре | 0-1 | 0 – юк;<br>1 – бар |
| Турыдан-туры катнашу | Цифрлы презентациянең һәм чыгышның тәңгәллеге (цифрлы презентация чыгышны визуаль мәгълүмат белән тулыландыра), чыгышта яңа мәгълүмат булу, халык алдында чыгыш ясау күнекмәсе | 0-10 | 0 – туры килми<br>10 – туры килә |
| Турыдан-туры катнашу | Экспертлар сорауларына җавапларның сыйфаты | 0-10 | 0 – катнашучы сорауларга җавап бирмәде яки тулы булмаган җаваплар бирде;<br>10 – катнашучы үзенә бирелгән сорауларга ышанычлы итеп, җентекле һәм дөрес җаваплар бирде |

Студентлар һәм аспирантлар арасында
Казан шәһәре Мэрының исемле
стипендияләренә дәгъва кылуга
фәнни-тикшеренү һәм фәнни-гамәли
эшләр конкурсы турында нигезләмәгә
9 номерлы кушымта

**Казан шәһәре Мэрының исемле стипендияләрен бирү буенча иҗтимагый совет составы**

| | |
|---|---|
| Заһидуллина Алия Рөстәм кызы | Иҗтимагый совет рәисе, Казан шәһәре Башкарма комитетының Балалар һәм яшьләр эшләре комитеты рәисе |
| Фёдорова Тамара Трофимовна | Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасының Мәгариф, фән һәм мәгърифәт эшчәнлеген үстерү комиссиясе рәисе (килешү буенча) |
| Абделганиева Диана Илдар кызы | Казан дәүләт медицина университеты проректоры (килешү буенча) |
| Әхмәтова Ирина Гәрәй кызы | Казан дәүләт энергетика университетының үсеш һәм инновацияләр буенча проректоры (килешү буенча) |
| Бабушкин Виталий Михайлович | А.Н.Туполев исемендәге Казан милли тикшеренү техник университетының (КНИТУ-КАИ) беренче проректоры – фәнни һәм инновацион эшчәнлек буенча проректоры (килешү буенча) |
| Вилданов Илфак Әлфикъ улы | Казан дәүләт архитектура-төзелеш университетының мәгариф эшчәнлеге буенча проректоры (килешү буенча) |
| Гарифуллина Резеда Сәет кызы | Казан дәүләт мәдәният институтының фәнни эш буенча проректоры (килешү буенча) |
| Гречанникова Наталья Вадимовна | Идел буе дәүләт физик культура, спорт һәм туризм университетының административ эш, социаль үсеш һәм яшьләр сәясәте буенча проректоры (килешү буенча) |
| Гомәров Ленар Әсхәт улы | В.М.Лебедев исемендәге Россия дәүләт гадел хокук университетының Казан филиалы директорының беренче урынбасары (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Дмитриев Андрей Владимирович | Казан дәүләт аграр университетының укыту эше һәм цифрлаштыру буенча проректоры (килешү буенча) |
| Найда Анна Михайловна | «ТИСБИ» идарә университетының беренче проректоры (килешү буенча) |
| Никитин Сергей Геннадиевич | В.Г.Тимирясов исемендәге Казан инновация университетының фәнни эш буенча проректоры ярдәмчесе (килешү буенча) |
| Солтанова Дилбәр Шамил кызы | Казан милли тикшеренү технология университетының уку-укыту эшләре буенча проректоры (килешү буенча) |
| Таюрский Дмитрий Альбертович | Казан (Идел буе) федераль университетының беренче проректоры – фәнни эшчәнлек буенча проректоры (килешү буенча) |
| Абдуллина Чулпан Зөфәр кызы | Татарстан Фәннәр академиясенең аспирантура һәм квалификацияне күтәрү бүлеге башлыгы (килешү буенча) |

Студентлар һәм аспирантлар арасында
Казан шәһәре Мэрының исемле стипендияләренә
дәгъва кылуга фәнни-тикшеренү һәм фәнни-гамәли
эшләр конкурсы турында нигезләмәгә
10 номерлы кушымта
(Форма)

**Конкурсның турыдан-туры катнашу этабын уздырганда эксперт советы әгъзалары өчен бәяләү бите**

| № | Катнашучының фамилиясе, исеме, атасының исеме (категория) | Эшнең исеме | Бәяләү критерийлары | | | | | Барлыгы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Эшнең актуальлеге | Проектны (эшне) гамәлгә ашыру һәм алга таба үстерү мөмкинлеге | Эшнең фәнни яктан яңалыгы | Цифрлы презентациянең һәм чыгышның тәңгәллеге (цифрлы презентация чыгышны визуаль мәгълүмат белән тулыландыра), чыгышта мәгълүмат булу, халык алдында чыгыш ясау күнекмәсе | Экспертлар сорауларына җавапларның сыйфаты | |
| | | | | | | | | |
| | | | | | | | | |
| | | | | | | | | |